КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 май г.Казань № 383

2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре аларның финанслар белән тәэмин итү

чыганагы булган башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 12 апрелендәге 484 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен;

2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен.

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 14 май, 383 нче
карары белән расланды

2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибе

1. Бу Тәртип 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне (алга таба – стимуллаштыру характерындагы түләүләр) гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансферт чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Башка бюджетара трансферт чаралары 2020 елның апрелендә – июнендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны профилактикалау һәм аның таралу рискын киметү чараларын тормышка ашыру максатларында медицина оешмалары эшен оештыруның вакытлыча тәртибе нигезендә COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга фактта медицина ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларында һәм аларның структур (шул исәптән ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүче) бүлекчәләрендә (алга таба – медицина оешмалары) стимуллаштыру характерындагы түләүләрне тәэмин итүгә җибәрелә.

3. Бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тора.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы башка бюджетара трансферт чараларын бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга җибәрә.

5. Башка бюджетара трансферт чараларын тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси исәп аша гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәре җиткерелгәннән соң финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 2020 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру максатларында:

медицина оешмалары белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясындагы 1 нче пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясындагы 1 нче пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә субсидияләр бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2016 ел, 22 декабрь, 17-148 нче боерыгы белән расланган форма буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатлар өчен Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр төзи;

медицина оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчасын күчерә.

8. Медицина оешмалары ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның икенче көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча субсидияләрдән файдалану турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына хисаплар кертә.

9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина оешмаларының бирелгән субсидия акчасын түбәндәге очракларда кире кайтаруын тәэмин итә:

субсидия акчасына ихтыяҗ булмаганда (кимегәндә);

медицина оешмалары тарафыннан дөрес булмаган хисаплылык тапшырылганда;

медицина оешмалары тарафыннан субсидия акчасы максатчан файдаланылмаганда.

10. Бу Тәртипнең 9 нчы пунктында күрсәтелгән очракларда, медицина оешмаларына бирелгән субсидия акчасы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбе алынган көннән 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары тарафыннан субсидия акчасын кире кайтару вакытлары бозылганда, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу пунктның беренче абзацы белән билгеләнгән вакыт тәмамланган көннән 30 көн эчендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

11. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә кергән башка бюджетара трансферт акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны тәэмин итә.

12. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы финанслар белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турындагы хисапны Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән Башка бюджетара трансферт бирү турындагы килешүдә билгеләнгән форма буенча һәм вакытларда иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасына урнаштыра.

13. Башка бюджетара трансферт акчасын максатчан файдаланмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

14. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына башка бюджетара трансфертның файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 14 май, 383 нче
карары белән расланды

2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибе

1. Бу Тәртип 2020 елда COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләргә аеруча мөһим эшләр башкарган өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрне (алга таба – стимуллаштыру характерындагы түләүләр) бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларының (алга таба – медицина оешмалары) COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнар белән турыдан-туры эшләүче медицина һәм башка хезмәткәрләренә түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

а) COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүче: табибларга – аена 50,0 мең сум күләмендә, урта медицина персоналына, кече медицина персоналына һәм ашыгыч медицина ярдәме транспортын йөртүчеләргә – аена 25 мең сум күләмендә;

б) COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче: табибларга – аена 80,0 мең сум күләмендә, урта медицина персоналына – аена 50,0 мең сум күләмендә, кече медицина персоналына – аена 25 мең сум күләмендә.

3. Медицина оешмалары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килештерелгән локаль норматив акт белән түбәндәгеләрне билгели:

а) аларда эшләү стимуллаштыру характердагы түләүләрне билгеләү хокукы бирә торган медицина оешмаларының структур бүлекчәләре исемнәре исемлеген;

б) аларда эшләү стимуллаштыру характердагы түләүләрне билгеләү хокукы бирә торган медицина оешмаларының структур бүлекчәләре медицина хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеген;

в) фактта эшләнгән вакыт өчен били торган вазыйфа нигезендә стимуллаштыру характерындагы түләү, әмма бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән күләмнәрдән югары булмаган күләмен;

г) стимуллаштыру характерындагы түләү билгеләнә торган вакытны.

4. Медицина оешмалары стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән акчаны максатчан файдалану өчен җавап бирә.